**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 декабрь № 1032

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 24 август, 706 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ – $3^5$ нче пунктлар өстәргә:

«$3^1$. Субсидияләр дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча

вакытында түләнмәгән кредит бурычлары булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә.

$3^2$. Субсидияне алу өчен, коммерциягә карамаган оешмалар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

субсидия бирү турында гариза;

финанс-икътисадый нигезләмәне теркәп, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә чыгымнар сметасын;

гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча вакытында түләнмәгән кредит бурычлары булмау турында документ.

$3^3$. Министрлык:

кертелгән көнне гаризаны терки;

теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә кертелгән документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә.

$3^4$. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең $3^3$ нче пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын кертү;

коммерциягә карамаган оешманың әлеге Тәртипнең $3^3$ нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

$3^5$. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, аны кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Министрлык, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, коммерциягә карамаган оешмага документларын кире кайтара.»;

4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык, субсидияне бирү турында карар кабул иткән көннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә коммерциягә карамаган оешма белән субсидия бирү турында килешү төзи.

Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, Татарстан Республикасында җирле үзидарәне формалаштыруга һәм үстерүгә булышлык күрсәтүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнарның төрләре, субсидияне күчерү тәртибе, субсидиядән файдалану турында хисап кертү тәртибе һәм вакытлары, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган өлешен агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кайтару очраклары, Министрлыкның субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең субсидия алучы тарафыннан үтәлүенә тикшерүләр үткәрүгә субсидия алучының ризалыгы, әлеге Тәртип һәм төзелгән килешү шартларының субсидия алучы тарафыннан үтәлүе турында нигезләмәләр күздә тотыла.»;

5 нче пунктта «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «килешү төзегән көннән соң 10 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидияләр түбәндәге очракларда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән 30 көн эчендә субсидия алучылар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар һәм документлар кертү;

субсидияләрдән файдалану турындагы хисапны билгеләнгән вакытта тапшырмау;

субсидия акчасын максатчан файдаланмау.»;

түбәндәге эчтәлекле $7^1$ – $7^3$ нче пунктлар өстәргә:

«$7^1$. Субсидия бирү турындагы килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдалынылмаган субсидияләрнең калган өлеше хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

$7^2$. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 7 һәм $7^1$ нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Министрлык субсидияне кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар кабул итә.

$7^3$. Министрлык субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең субсидия алучылар тарафыннан үтәлүенә законнар белән билгеләнгән тәртиптә тикшерү үткәрә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\1032.docx